СОВЕТ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Чехова, д.18, с. Верхний Услон, 422570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ
Чехов ур., 18 нче йорт, Югары ослан авылы, 422570

Тел.: (84379) 2-13-38, факс: (84379) 2-18-39, E-mail: sovet.uslon@tatar.ru, verhny-uslon.tatarstan.ru

РЕШЕНИЕ КАРАР

29.04.2020 с. Верхний Услон №57-654

## 2020 елның 1 кварталы өчен Югары Ослан муниципаль районы бюджеты үтәлеше турында

Югары Ослан муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы рәисе Е. Е. Колесованың 2020 елның 1 кварталында Югары Ослан муниципаль районы бюджеты үтәлеше турындагы мәгълүматын тыңлаганнан һәм фикер алышканнан соң,

Югары Ослан муниципаль районы Советы
карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районының 2020 елның 1 кварталы өчен бюджеты үтәлеше турында мәгълүматны игътибарга алырга (1 кушымта).

2. Тәкъдим итергә:

2.1. Муниципаль берәмлекләрнең Башкарма комитетлары, Финанс-бюджет палатасы, мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы белән берлектә, бюджетның барлык дәрәҗәләренә керемнәрне мобилизацияләү буенча эшне көчәйтергә һәм салым һәм салым булмаган керемнәр буенча план күрсәткечләрен максималь рәвештә үтәүне тәэмин итәргә;

2.2. 2020 елның ахырына кадәр һәм 2 кварталында керемнәрнең һәм бюджеттан тыш чараларның керемнәре кимү шартларында муниципаль берәмлекләрнең Башкарма комитетларына:

- бюджетларның беренчел һәм социаль әһәмиятле чыгымнары буенча чыгым йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итәргә, 2020 елның II яртыеллыгына, нигездә, 4 кварталга беренчел булмаган чыгымнарны кичерергә;

- җирле бюджетлар чыгымнарын оптимальләштерү һәм киметү, бюджет акчаларын сакчыл һәм экономияле тоту буенча реаль чаралар үткәрергә;

- бюджет акчаларының калган өлешен җибәрүгә катгый контроль булдырырга, җирле бюджетларның төшеп калучы керемнәрен компенсацияләү чыганакларын эзләргә, агымдагы ел азагына кадәр җирле бюджетларның кытлыксыз үтәлешен тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

Совет Рәисе,
Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль район Башлыгы М. Г. Зыятдинов

Югары Ослан муниципаль районы
Советының 2020 елның
29 апрелендәге 57-654 номерлы
карарына 1 кушымта

Югары Ослан муниципаль районының 2020 елның 1 кварталында берләштерелгән бюджеты үтәлеше, мең сум.

| Күрсәткеч атамасы | 2020 елга план | 2020 елның 1 кварталы факты | үтәлеш % |
|---|---|---|---|
| Җирле бюджет керемнәре | 613551,7 | 187874,0 | 30,6 |
| 1.Салым керемнәре | 240279,8 | 56098,1 | 23,3 |
| 1.1 физик затлар кеременә салым | 125879,8 | 27496,5 | 21,8 |
| 1.2 акцизлар түләүдән кергән керемнәр | 31000,0 | 7529,5 | 24,3 |
| 1.3 салым салуның гадиләштерелгән системасын куллануга бәйле рәвештә алына торган салым | 12043,0 | 2494,1 | 20,7 |
| 1.4 эшчәнлекнең аерым төрләре өчен кертелгән керемгә бердәм салым | 4561,0 | 1114,6 | 24,4 |
| 1.5 бердәм авыл хуҗалыгы салымы | 117,0 | 82,3 | 70,3 |
| 1.6 салым салуның патент системасын куллануга бәйле рәвештә алына торган салым | 156,1 | 56,9 | 36,4 |
| 1.7 физик затлар милкенә салым | 5155,0 | 452,1 | 8,8 |
| 1.8 җир салымы | 57709,9 | 16496,1 | 28,6 |
| 1.9 файдалы казылмалар чыгаруга салым | 1243,0 | 44,7 | 3,6 |
| 1.10 дәүләт пошлинасы | 2415,0 | 331,3 | 13,7 |
| 1.11 башка | - | - | - |
| 2. Салым булмаган керемнәр | 11986,6 | 12968,9 | 108,2 |
| 2.1 дәүләт һәм муниципаль милектәге мөлкәтне файдаланудан керемнәр | 6705,0 | 2750,7 | 41,0 |
| 2.2 әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясаган өчен түләү | 203,0 | 121,0 | 59,6 |
| 2.3 башка керемнәр | 5078,6 | 10097,2 | 198,8 |
| 3.Түләүсез керемнәр | 361285,3 | 118807,0 | 32,9 |
| 3.1 башка дәрәҗәдәге бюджетлардан кире кайтарылмый торган керемнәр | 361285,3 | 130819,2 | 36,2 |
| 3.1.1 дотацияләр | 35728,2 | 11909,3 | 33,3 |
| 3.1.2 субсидияләр | 188046,8 | 77780,9 | 41,4 |
| 3.1.3 субвенцияләр | 137144,2 | 40902,9 | 29,8 |
| 3.1.4 башка бюджетара трансфертлар | 366,1 | 226,1 | 61,8 |
| 3.2 башка кире кайтарылмый торган кертемнәр | - | 5,0 | - |
| 3.3 Субсидияләрнең, субвенцияләрнең | | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| һәм башка бюджетара трансфертларның калдыкларын кире кайтарудан керем | - | 77,0 | - |
| 3.4 Узган елларның максатчан билгеләнеше булган субсидияләр, субвенцияләр һәм бюджетара трансфертларның калдыкларын кире кайтару | - | -12094,2 | - |
| Җирле бюджет чыгымнары | 649849,3 | 187450,1 | 28,9 |
| 1.Гомумдәүләт мәсьәләләре | 101670,7 | 24882,1 | 24,5 |
| 2.милли оборона | 1749,4 | 437,4 | 25,0 |
| 3.Милли иминлек һәм хокук саклау эшчәнлеге | 4740,7 | 270,6 | 5,7 |
| 4.милли икътисад | 52763,2 | 4234,0 | 8,0 |
| 5.торак-коммуналь хуҗалык | 22541,6 | 4970,2 | 22,1 |
| 6.әйләнә-тирә мохитне саклау | 1646,0 | - | - |
| 7.мәгариф | 349501,8 | 119613,6 | 34,2 |
| 8.мәдәният,кинематография һәм массакүләм мәгълүмат чаралары | 75578,5 | 22641,3 | 30,0 |
| 9.сәламәтлек саклау | 254,4 | 76,3 | 30,0 |
| 10.социаль сәясәт | 12637,4 | 2893,6 | 22,9 |
| 11.физик культура һәм спорт | 24298,8 | 6089,7 | 25,1 |
| 12.бюджетара трансфертлар | 2466,8 | 1341,3 | 54,4 |
| Профицит (+), дефицит (-) | -36297,6 | 423,9 | -1,2 |